ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 09 2020 г. № 192

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгының 2017 елның 22 апрелендә кабул ителгән 82нче номерлы «Балтач муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирлегендә эшләүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Мәгариф турында Татарстан Республикасы Законының 14 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2020 елның 18 июлендәге 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Балтач муниципаль районы башлыгы **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгының 2017 елның 22 апрелендә кабул ителгән 82-нче номерлы «Балтач муниципаль районының шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирлегендә эшләүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында»гы карарына түбәндәге өстәмә кертергә:

карарның 1-нче пункын 1.1 пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«белем бирү оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, дәүләт мәгариф учреждениеләрендә эшләүче һәм авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче торак урыннары, җылылык һәм ут өчен түләүгә субсидияләр бирү».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: baltasi.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль
районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин